КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 февраль г.Казань № 59

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 9 июнь, 453 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 май, 379 нчы; 2011 ел, 9 август, 645 нче; 2012 ел, 29 ноябрь, 1045 нче; 2013 ел, 12 март, 158 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 812 нче; 2014 ел, 26 ноябрь, 918 нче; 2015 ел, 23 июнь, 457 нче; 2015 ел, 21 октябрь, 790 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 423 нче; 2016 ел, 13 август, 558 нче; 2017 ел, 1 март, 123 нче; 2017 ел, 5 август, 556 нчы; 2017 ел, 15 август, 571 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 742 нче; 2018 ел, 26 апрель, 286 нчы, 2018 ел, 29 декабрь, 1296 нчы, 2020 ел, 21 август, 719 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «кушымтада бирелә торган» сүзләрен «кушып бирелә торган» сүзләренә алмаштырырга, «һәм аның структурасын» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе  хезмәткәрләренең чик санын билгеләргә:

2018 елның 1 апреленнән – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 2 687,937 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 215 берәмлек;

2020 елның 1 октябреннән – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 2 768,470 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 215 берәмлек күләмендә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданк хәле актларын теркәү идарәсе турындагы нигезләмәдә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Идарә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән мәдәният өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салуны (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихый-мәдәни мирасны саклау һәм файдалану), төрле диннәрнең дини берләшмәләре арасында үзара аңлашуны һәм сабырлыкны ныгытуга ярдәм күрсәтү функциясен гамәлгә ашырганда (04.03*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру функциясен тормышка ашырганда (04.05.03*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне тормышка ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән социаль яклау белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (04.06*);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02*);

Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2 *);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04*).»;

3.3.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.6. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә мәгълүматлаштыруны оештыра һәм тәэмин итә.»;

3.3.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.10 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар чыгару;»;

алтынчы абзацта «законнар тәртибендә» сүзләреннән соң «, хокукый экспертиза уздыру, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларны анализлау» сүзләрен өстәргә;»;

3.3.11 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.11. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга үзләренә тапшырылган вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашыруларын, граждан хәле актлары турындагы законнар таләпләренең түбәндәге өлештә үтәлүен үз компетенциясе чикләрендә тикшереп тора:»;

җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«граждан хәле актларын теркәгәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

граждан хәле актларын теркәү органнарында граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәве китапларын саклауның тиешле шартларын тудыру;

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә граждан хәле актлары язмаларыннан йөз ел узгач кәгазьдә җыелган гражданлык хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын тапшыру.»;

3.3.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.12. Граждан хәле актларын дәүләт теркәве эшчәнлеген оештыруны һәм аны методик һәм консультация белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра.»;

3.3.13 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.14 пунктының беренче абзацында «йөз ел» сүзләреннән соң «һәм юкка чыгару» сүзләрен өстәргә;

3.3.20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.20. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәтләрен электрон рәвештә күрсәтүне оештыру белән идарә итә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплау рәвешләрен һәм срокларын раслау хакында» 2008 ел, 22 декабрь, 907 нче;

«Граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын электрон формага күчерүне оештыру турында» 2017 ел, 15 декабрь, 998 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын электрон формага күчерүне оештыру турында» 2017 ел, 15 декабрь, 998 нче карары белән расланган Граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын электрон формага күчерүне оештыру буенча эшлщрне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 10 декабрь, 1102 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын электрон формага күчерүне оештыру турында» 2017 ел, 15 декабрь, 998 нче карары белән расланган Граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын электрон формага күчерүне оештыру буенча эшлщрне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 15 апрель, 292 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын электрон формага күчерүне оештыру турында» 2017 ел, 15 декабрь, 998 нче карары белән расланган Граждан хәле актларын (актлар китапларын) дәүләт теркәвенә алу китапларын электрон формага күчерүне оештыру буенча эшлщрне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 30 декабрь, 1269 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин